# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Халыкны эш белән тәэмин итү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>I статья.</u> "Халыкны эш белән тәэмин итү турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, N 3, 1994, N 7), түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Халыкны эш белән тәэмин итү турында"

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Әлеге Закон халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт сәясәтенең хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы гражданнарының хезмәткә булган хокукларын һәм эшсезлектән социаль яклану хокукларын гамәлгә ашыруда дәүләт гарантияләрен билгели.

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Гражданнарның эш белән тәэмин ителеше

1. Эш белән тәэмин ителеш - гражданнарның шәхси һәм иҗтимагый ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә бәйле һәм законнарга каршы килмәүче, кагыйдә буларак, аларга хезмәт хакы, хезмәт кереме (алга таба - хезмәт хакы) китерүче эшчәнлеге ул.

2. Татарстан Республикасы гражданнары хезмәткә сәләтләрен фәкать үзләре генә файдалану хокукына ия. Мәҗбүри хезмәт

бары тик законнарда билгеләнгән тәртиптә генә рөхсәт ителә.

2 статья. Эш белән тәэмин ителгән гражданнар

Түбәндәге гражданнар эш белән тәэмин ителгән дип санала:

үзләрен мөстәкыйль рәвештә эш белән тәэмин итүчеләр;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыкларының җитештерү кооперативлары әгъзалары;

кимендә 0,25 гектар җир кишәрлеге булганнар;

ялланып (хезмәт шартнамәсе, контракт буенча) эшләүчеләр, шул исәптән тулы яисә тулы булмаган эш вакыты шартларында түләнә торган эш башкаручылар, шулай ук башка түләүле эше (хезмәте) булганнар, моңа сезонлы һәм вакытлы эшләр дә керә;

хезмәткә сәләтсез булуы, отпускка китүе, яңа һөнәргә өйрәнүе, белгечлеген күтәрүе, забастовка яки башка сәбәпләр аркасында җитештерүнең туктап торуы белән бәйле рәвештә эш урынында вакытлыча булмаучылар;

түләүле эш урынына сайланган, билгеләп куелган яки расланганнар;

хәрби хезмәт үтүчеләр, шулай ук дәүләт иминлеге һәм эчке эшләр органнарында хезмәт итүчеләр;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы юлламасы буенча белем алуны да кертеп, гомуми белем учреждениеләрендә, башлангыч һөнәр, урта һөнәр, югары һөнәр белеме бирү һәм башка мәгариф учреждениеләрендә көндез белем алучылар;

ярдәмче промыселларда эшләүчеләр һәм продукциясен шартнамәләр буенча сатучылар, шулай ук гражданлык-хокукый шартнамәләр (подряд шартнамәләре) буенча эш башкаручылар.

3 статья. Гражданнарны эшсезләр дип тануның тәртибе һәм шартлары

1. Эше һәм хезмәт хакы булмаган, үзенә яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында теркәлгән һәм эш эзләүче, эшкә керешергә әзер булган хезмәткә сәләтле гражданнар эшсезләр дип танылалар.

Бу чакта, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамас-

тан, оешмаларны, предприятиеләрне, учреждениеләрне (алга таба - оешмалар) ябу, хезмәткәрләрнең санын яисә штат кыскарту белән бәйле рәвештә эштән (хәрби хезмәттән) чыгарылган гражданнарга бирелә торган пособиеләр һәм уртача хезмәт хакы түләүләре исәпкә алынмый.

2. Үзенә яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән гражданны эшсез дип тану турындагы карар эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органына паспорт, хезмәт кенәгәсе яисә аларны алмаштыручы документлар, аның һөнәре буенча белгечлеген раслаучы документлар, соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен уртача хезмәт хакы турында белешмә, ә беренче мәртәбә эш эзләүчеләр (элегрәк бер дә эшләмәгәннәр) һәм һөнәре (белгечлеге) булмаганнар өчен - паспорт һәм белеме турында белешмә бирелгән мизгелдән башлап 11 көннән дә соңга калмыйча гражданның яшәү урынындагы эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы тарафыннан кабул ителә.

Соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен алынган уртача хезмәт хакы турындагы белешмә чит ил валютасында бирелгән очракта, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары граждан эштән чыгарылган көнне билгеләнгән рәсми курс буенча чит ил валютасын сумнарга (рубльләргә) күчерәләр.

Гражданнар үзләренә яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән көннән соң эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары 10 көн эчендә аларга яраклы эш табып бирә алмаганда, югарыда әйтелгән документларны күрсәткән беренче көннән алып бу гражданнар эшсез дип танылa.

Инвалидны эшсез дип тану турындагы карар инвалидларны социаль яклау турындагы законнар нигезендә эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тарафыннан кабул ителә.

3. Түбәндәге гражданнар эшсезләр дип танылa алмый:

16 яшькә җитмәгәннәр;

үзләренә яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында теркәлгәннән соң 10 көн эчендә үзләренә яраклы эшнең ике вариантыннан (вакытлыча эшне дә кертеп) баш тартучылар, ә һөнәри әзерлек алудан ике тапкыр баш тарткан яисә тәкъдим ителгән түләүле эштән ике тапкыр баш тарткан (вакытлыча эшне дә кертеп), һөнәре (белгечлеге) булмаган беренче тапкыр эш эзләүчеләр (элегрәк бер дә эш-

ләмәгәннәр). Гражданга бер үк һөнәр (белгечлек) буенча бер үк эш (һөнәри әзерлек) ике тапкыр тәкъдим ителә алмый;

яраклы эш эзләү максатларында теркәлгәннән соң яраклы эш тәкъдим ителгәндә эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарына 10 көн эчендә мәгълүм сәбәпләрсез килмәүчеләр, шулай ук эшсезләр сыйфатында теркәлү өчен эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары билгеләгән вакытта килмәүчеләр;

суд карары нигезендә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәзага хөкем ителүчеләр.

4. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылудан мәхрүм ителгән гражданнар үзләрен эшсез дип тану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарына ике атнадан соң кабат мөрәҗәгать итәргә хаклы.

<u>4 статья.</u> Яраклы һәм яраксыз эш

1. Һөнәренә, һөнәри әзерлек дәрәҗәсенә, аның соңгы эш урыны шартларына (түләүле җәмәгать эшләреннән гайре), сәламәтлегенә туры килерлек, эш урынына транспортта барып җитәрлек эш (моңа вакытлыча эш тә керә) яраклы эш, дип санала.

2. Эшсезнең яшәү урыныннан алып яраклы эшкә кадәрге юлының максималь ераклыгы, әлеге урындагы җәмәгать транспорты челтәре үсешен исәпкә алып, тиешле җирле администрация тарафыннан билгеләнә.

3. Хезмәт турындагы законнарның таләпләренә җавап бирерлек алдан әзерлекне (гражданнарның яшен һәм башка үзенчәлекләрен) таләп итүче яисә таләп итмәүче түләүле эш, моңа вакытлы эш тә керә, түбәндәге категория гражданнар өчен яраклы, дип санала:

беренче мәртәбә эш эзләүчеләр (элегрәк бер дә эшләмәгәннәр) һәм һөнәре (белгечлеге) булмаганнар;

хезмәт дисциплинасын бозган өчен эштән чыгарылганнар, шулай ук озак вакыт (бер елдан артык) эшләмәгәннән соң хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрергә омтылучылар;

өч ел буе эшләмәгәннән соң яки эшсезлекнең башлангыч (12

айлык) чоры тәмамланганнан соң булган һөнәрләре (белгечлекләре) буенча белгечлекләрен арттырудан (торгызудан), икенче бер һөнәр үзләштерүдән яисә яңа һәнәргә өйрәнүдән баш тартучылар;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында 18 айдан артыграк исәптә торучылар, шулай ук өч елдан артыграк эшләмичә торучылар;

суд карары нигезендә төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәр.

4. Түбәндәге эш яраксыз, дип санала, әгәр:

бу эш гражданның яшәү урынын үз ризалыгыннан гайре алмаштыруга бәйле булса;

хезмәт шартлары хезмәтне саклау нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килмәсә;

тәкъдим ителүче хезмәт хакы гражданның соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен исәпләнелгән уртача хезмәт хакыннан азрак булса. Уртача айлык хезмәт хакы Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан арткан гражданнарга мондый нигезләмә кагылмый. Бу очракта тәкъдим ителүче хезмәт хакы Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан азрак булса, эш яраклы, дип санала алмый.

## 5 статья. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәте

1. Татарстан Республикасы гражданнарының эш белән тулысынча, нәтиҗәле һәм иреклe тәэмин ителү хокукын гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү буенча Россия Федерациясе белән бер үк сәясәт уздыра.

2. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәте түбәндәгеләргә юнәлдерелә:

хезмәт ресурсларын үстерүгә;

Татарстан Республикасының барлык гражданнарына, милләтенә, җенесенә, яшенә, социаль хәленә, сәяси инануларына һәм дини мәслөгенә карамастан, үзе теләгән хезмәткә һәм эшне ирекле сайлап алуга хокукын тормышка ашыруда тигез мөмкинлекләр тәэмин итүгә;

гражданнарның законлылык кысаларында тормышка ашырыла торган хезмәт һәм эшкуарлык инициативасын хуплауга, аларның

җитештерүчән һәм иҗади хезмәткә сәләтләрен үстерүгә ярдәм күрсәтүгә;

хезмәтнең ихтыярилыгын тәэмин итүгә;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль яклауны тәэмин итүгә, социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны (инвалидларны, шуңа вәкаләтле орган бәяләмәсе буенча үз тәрбияләвендә даими карап торуны, ярдәм күрсәтүне яисә күзәтүне таләп итүче затлары булган гражданнарны; ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны; беренче мәртәбә эш эзләүче 18 яше тулмаган яшьләрне; пенсия алды яше җиткән (картлык (яше буенча) пенсиясе алу хокукын бирерлек яшькә җитәргә ике ел кала) затларны; качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләрне; хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын; балигъ булмаган балалар, гарип балалар тәрбияләүче ялгызак һәм күп балалы ата-аналарны; ата-анасының икесе дә эшсез дип танылган гаиләләрне; Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре, афәтләре нәтиҗәсендә радиация йогынтысы кичергән гражданнарны) эш белән тәэмин итәргә булышырлык махсус чаралар үткәрүгә;

халыкны эш белән тәэмин итүдә җирле администрация органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөстәкыйльлеге һәм эш белән тәэмин итүдәге аеруча мөһим проблемаларны хәл итү буенча үзәкләштерелгән гамәлләрне килештерүнең бергә алып барылуына;

инвестиция-структура сәясәтен, социаль тәэминатны, керемнәрнең артуын һәм аларны бүлүне җайга салуны, инфляцияне кисәтүне дә кертеп, эш белән тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлекне икътисадый һәм социаль сәясәтнең башка юнәлешләре буенча эшчәнлек белән яраштыруга;

гамәлдәге эш урыннарын саклап калучы һәм, барыннан да бигрәк, социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар өчен яңа эш урыннары булдыручы эш бирүчеләрне кызыксындыруга;

массакүләм эшсезлекне кисәтүгә һәм озакка сузылган (бер елдан артыграк) эшсезлекне кыскартуга;

халыкны эш белән тәэмин итү гамәлләрен әзерләүдә һәм тормышка ашыруда дәүләт органнарының, һөнәр берлекләренең, хезмәткәрләрнең башка вәкиллекле органнарының һәм эш бирүчеләренең эшчәнлеген яраштыруга һәм аларны тикшереп торуга;

Татарстан Республикасы гражданнарының республикадан читтәге һәм чит ил гражданнарының Татарстан Республикасы территориясендәге хезмәт эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләрне дә кертеп, халыкны эш белән тәэмин итү проблемаларын хәл итүдә халыкара һәм республикаара хезмәттәшлеккә, халыкара хезмәт нормаларын үтәүгә.

6 статья. Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар

1. Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар әлеге Законнан, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка законнардан һәм норматив-хокукый актлардан гыйбарәт.

2. Әгәр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә башкасы каралмаган булса, халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар шулай ук чит ил гражданнарына һәм гражданлыксыз затларга да кагыла.

П бүлек. Гражданнарның эш белән тәэмин ителү хокуклары

7 статья. Гражданнарның эш урынын сайлап алу хокукы

1. Татарстан Республикасы гражданнары эш бирүчегә (оешма (юридик зат) йә граждан хезмәт мөнәсәбәтләренә керүче физик зат) турыдан-туры мөрәҗәгать итү юлы белән яки эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының бушлай арадашлык итү юлы белән яисә халыкны эшкә урнаштыручы башка оешмалар ярдәме белән эш урынын сайлап алу хокукына ия.

2. Эшкә алу турындагы карар эш бирүче белән эшкә алынучы зат арасындагы хезмәт шартнамәсен (контрактын) төзү юлы белән кабул ителә.

Эшкә урнашканда хезмәт шартнамәләрен (контрактларын) төзүнең тәртибе һәм шартлары хезмәт турындагы законнар белән җайга салына.

8 статья. Гражданнарның эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында консультация алу, һөнәри юнәлеш, һөнәри әзерлек алу, яңа һөнәргә өйрәнү, белгечлекне арттыру һәм мәгълүмат алу хокукы

1. Гражданнар, шул исәптән 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар да, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында эшчәнлек төрен сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри әзерлек алу мөмкинлеге максатларында бушлай консультация һәм бушлай мәгълүмат алу хокукына ия.

2. Эшсез гражданнар эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча шулай ук бушлай һөнәри юнәлеш, психологик ярдәм, һөнәри әзерлек алу, яңа һөнәргә өйрәнү һәм белгечлеген арттыру хокукына ия.

9 статья. Татарстан Республикасы гражданнарының Татарстан Республикасы территориясеннән читтә һөнәри эшчәнлеккә хокукы

Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы территориясеннән читтә мөстәкыйль рәвештә эш эзләргә һәм эшкә урнашырга хаклы.

10 статья. Гражданнарның эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының һәм аларның урындагы затларының гамәлләренә карата шикаять белдерү хокукы

Гражданнар эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының һәм аларның урындагы затларының карарларына, гамәлләренә һәм гамәл кылмауларына карата эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча югарырак органга, шулай ук судка законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## III бүлек. Халыкны эш белән тәэмин итү әлкәсендә дәүләт гарантияләре

**11 статья.** Гражданнарның хезмәткә хокукын гамәлгә ашыруда дәүләт гарантияләре

1. Дәүләт гражданнарга түбәндәгеләрне гарантияли:

эшчәнлек төрен сайлап алу ирекен, шул исәптән хезмәт режимы төрле булганнарын да;

хезмәтне саклауны, сәбәпсез эштән чыгарылудан һәм башка эшкә (эш урынына) күчерелүдән яисә эшкә алганда гражданнан сәбәпсез баш тартудан хезмәт турындагы законнар нигезендә хокукый яклануны;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт органнары арадашлыгы белән яраклы эшне сайлап алуга һәм эшкә урнашуга бушлай ярдәм итүне.

2. Эшсез гражданнарга дәүләт түбәндәгеләрне гарантияли:

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча бушлай һөнәри юнәлеш алуны, яңа һөнәргә (белгечлеккә) өйрәнүне, белгечлекне арттыруны яки стипендия түләп укытуны;

социаль ярдәм тәэмин итүне;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тәкъдиме буенча башка җиргә эшкә (укырга) җибәрелү уңаеннан матди чыгымнарны гамәлдәге законнар нигезендә компенсацияләүне;

гражданнарның яшен һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла торган түләүле җәмәгать эшләрендә һәм вакытлы эшләрдә катнашу турында вакыты билгеләнгән хезмәт шартнамәләре (контрактлары) төзү мөмкинлеген;

эшкә алынганда һәм укырга җибәрелгәндә бушлай медицина хезмәтен һәм медицина таныклавын.

**12 статья.** Халыкның аерым категорияләре өчен эш белән тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре

1. Дәүләт социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарга эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү буенча максатчыл программалар әзерләү һәм аларны га-

мәлгә ашыру, өстәмә эш урыннары булдыру һәм махсуслаштырылган оешмалар төзү (моңа инвалидлар хезмәте өчен оешмалар да керә), һөнәри юнәлеш хезмәтләре күрсәтү юлы белән, махсус программалар буенча һөнәргә өйрәтүне оештыру юлы белән, шулай ук гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең оешмаларда эшләүчеләрнең гомуми саныннан 5 процентка кадәрен, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы законнар нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен оешмаларга карата квота билгеләү юлы белән өстәмә гарантияләр тәэмин итә.

2. Хезмәткәрләр санын яисә штатларны кыскарту аркасында оешмалардан эштән азат ителүче гражданнарга торак алганчы элеккеге эш урынында торак алу (торак шартларын яхшырту) чиратын саклап калу, шулай ук дәвалау учреждениеләреннән файдалану мөмкинлеге, ә балаларына исә мәктәпкә кергәнче балалар учреждениеләренә йөрү мөмкинлеге әлеге оешмада эшләүче гражданнар белән бертигез шартларда гарантияләнә.

3. Хәрби хезмәткәрләрнең һәм хәрби хезмәттән киткәннәрнең хатыннары (ирләре), башка бертигез шартлар белән бергә, дәүләт предприятиеләренә эшкә урнашканда өстенлекле хокукка ия булалар.

4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм дәүләт идарәсенең җирле органнары аерым очракларда гына, хезмәткәрләрне күпләп азат итү булганда, аларны хезмәткә урнаштыру кыенлашкан очракта эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары, һөнәр берлекләре органнары тәкъдиме буенча аларны эштән азат итү турындагы карарны алты айга кадәр туктатып торырга яки хезмәткәрләрне дәүләт унитар предприятиеләреннән эштән азат итүне ел дәвамында этаплап үткәрергә мөмкин.

## IV бүлек. Халыкны эш белән тәэмин итүне җайга салу һәм оештыру

### 13 статья. Халыкны эш белән тәэмин итүне җайга салу

Халыкның тулысынча, нәтиҗәле һәм ирекле сайлап алынган эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү максатларында дәүләт түбәндәгеләрне башкара:

җитештерүче көчләрне нәтиҗәле урнаштыруга, хезмәт ресурс-

ларының хәрәкәтчәнлеген арттыруга, эш белән вакытлыча һәм мөстәкыйль тәэмин ителешне үстерүгә юнәлдерелгән финанс-кредит, инвестиция һәм салым сәясәте чараларын, эш урыннары системасын саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм итәрлек башка чараларны әзерләүне;

гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү, аларга тиешле дәүләт гарантияләре бирү, халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны киләчәктә дә камилләштерү нигезендә эш белән тәэмин итү өлкәсендә хокукый җайга салуны;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының бердәм системасын булдыруны;

эш белән мәшгуль булмаган халыкны эш белән тәэмин итүгә һәм социаль яклауга ярдәм күрсәтүнең республика, шәһәр һәм район программаларын әзерләүне һәм гамәлгә ашыруны.

<u>14 статья.</u> Халыкны эш белән тәэмин итү турында дәүләт статистика хисабы һәм мәгълүмат

Хезмәт базары халәтен һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хәлне объектив бәяләү өчен дәүләт статистика хисабы урнаштырыла.

Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары дәүләт статистика органнары белән, салым органнары, миграция хезмәте органнары һәм башка кызыксынучы дәүләт органнары белән хисап документларын һәм үз вазыйфаларын үтәү өчен һәр якка да кирәкле белешмәләрне бушлай алмашалар.

<u>15 статья.</u> Эш белән мәшгуль булмаган халыкка эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү һәм аларны социаль яклау программалары

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, җирле администрацияләр халыкны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү һәм эшсезлектән социаль яклау гамәлләрен күз алдында тотучы республика, шәһәр һәм район программаларын әлеге Закон нигезендә әзерлиләр һәм аларны тиешенчә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, халык депутатларының җирле Советлары раславына чыгаралар һәм аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр.

16 статья. Өстенлекле үсешкә ия территорияләр

1. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, җирле администрацияләр белән үзара килешеп, эш урыннарын арттыру дәүләт тарафыннан аеруча хуплана торган территорияләрне билгеләр. Мондый территорияләргә (барыннан да бигрәк эш көчләре күп булган территорияләргә), шулай ук авыл районнарына билгеле бер чорга өстенлекле үсешкә ия территорияләр статусы бирелә.

Өстенлекле үсешкә ия территория статусын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый.

2. Югарыда күрсәтелгән территорияләрдә производстволар, филиаллар һәм эш урыннары, социаль инфраструктура объектлары булдыручы эш бирүчеләргә табышка салым ташламалары бирелә, законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда башка төрле финанс һәм матди ярдәм күрсәтелә.

17 статья. Гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын үз теләкләре буенча күчерү

Гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын үз теләкләре буенча күчерү эш белән тәэмин итү проблемасын хәл итү рәвешләренең берсе булып тора, һәм ул халык аз урнашкан районнарда авыл хуҗалыгы җитештерүен хезмәт ресурслары белән тәэмин итү максатларында үткәрелә. Бу районнарга күчүче гражданнарга дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтү гамәлләре, гаиләләр саны һәм гаиләләр күчү белән бәйле финанс чыгымнары эш белән мәшгуль булмаган халыкны Эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау буенча республика программасында билгеләнә.

18 статья. Татарстан Республикасына чит илләрнең эшче көчләрен җәлеп итү

Татарстан Республикасы территориясендә чит илләрнең эшче көчләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану законнар нигезендә башкарыла.

19 статья. Халыкны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү эшчәнлеген лицензияләү

Гражданнарны эшкә урнаштыру, аларга һәнәри юнәлеш бирү буенча хезмәт күрсәтү, эшсез гражданнарга һәм эш белән мәшгуль булмаган халыкка ярдәм күрсәтү эшчәнлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты тарафыннан бирелүче лицензияләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

20 статья. Эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүче координация комитетлары

Халыкны эш белән тәэмин итү сәясәтен билгеләү һәм аны гамәлгә ашыру буенча үзара килештерелгән карарлар әзерләү максатларында һөнәр берлекләре берләшмәләре, хезмәткәрләрнең башка вәкиллекле органнары, эш бирүчеләр, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары, шулай ук дәүләтнең кызыксынучы башка органнары һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган гражданнарның мәнфәгатьләрен чагылдыручы җәмәгать оешмалары вәкилләреннән социаль партнерлык кысаларында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүче республика, шәһәр һәм район координация комитетлары төзелә.

Комитетларны оештыру һәм аларның эш тәртибе комитетларда вәкил булган яклар тарафыннан билгеләнә.

21 статья. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүдә һөнәр берлекләренең һәм башка вәкиллекле органнарның катнашуы

1. Һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләрнең башка вәкиллекле органнары дәүләтнең халыкны эш белән тәэмин итү сәясәтен әзерләүдә катнашырга хаклы.

2. Һөнәр берлекләре оешмалары һәм хезмәткәрләрнең башка вәкиллекле органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

республикада, шәһәрдә, районда халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен исәпкә алып, хезмәткәрләрне дәүләт унитар предприятиеләреннән эштән күпләп азат итүгә бәйле гамәлләрне

тормышка ашыруның вакытын күчерү яки аны вакытлыча туктатып тору турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, җирле администрацияләргә, җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;

эш белән тәэмин итү, эшкә (хезмәткә) алу һәм эштән азат итү, законнар нигезендә өстенлекле ташламалар һәм компенсацияләр бирү мәсьәләләрендә хезмәт ияләренең социаль гарантияләрен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

3. Җитештерүне нәтиҗәлерәк итү, хезмәтне оештыруны камилләштерү, оешманы яисә аның структур бүлекчәләрен ябу һәм аларның юнәлешен үзгәртү, эш бирүче инициативасы буенча җитештерүне тулысынча яки өлешчә туктатып торуга бәйле рәвештә хезмәткәрләрне эштән күпләп азат итү бары тик тиешле һөнәр берлекләре органнарына һәм хезмәткәрләрнең вәкиллекле башка органнарына алдан (кимендә өч ай алдан) язмача хәбәр иткән килеш кенә гамәлгә ашырыла ала.

4. Дәүләт идарәсе органнары, эш бирүчеләр һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләрнең вәкиллекле органнары тәкъдиме буенча эш белән тәэмин итү проблемаларына кагылышлы үзара консультацияләр үткәрәләр.

Консультация йомгаклары буенча халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән гамәлләрне күз алдында тотучы килешүләр төзелергә мөмкин.

5. Һөнәр берлекләре һәм хезмәткәрләрнең вәкиллекле башка органнары эш бирүчедән эш белән тәэмин итүнең конкрет чараларын күмәк шартнамәгә кертүне таләп итәргә хокуклы.

6. Һөнәр берлекләренең һәм хезмәткәрләрнең вәкиллекле башка органнарының тәкъдимнәре законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

<u>22 статья.</u> Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды

1. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды Татарстан Республикасының эш белән мәшгуль булмаган халкын эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау программасын тормышка ашыруга бәйле гамәлләрне финанслау өчен булдырыла. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт

фондының акчалары башка максатларга юнәлдерелә алмый.

2. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә: эш бирүчеләрнең мәҗбүри иминләштерү кертемнәре; эшләүчеләрнең хезмәт хакыннан мәҗбүри иминләштерү кертемнәре, Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар ассигнованиеләре (кирәк чакта); юридик һәм физик затларның, чит илләрнеке дә, ирекле кертемнәре; законнарда күрсәтелгән таләпләрне бозган өчен эш бирүчеләрдән эзләтеп алынучы суммалар рәвешендәге башка кертемнәр.

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына иминләштерү кертемнәрен исәпләүнең дөреслеген, вакытында кертелүен һәм тулысынча кертелүен тикшереп тору Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясенә йөкләнә.

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды акчалары Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының вәкаләтле банк учреждениеләре счетларына туплана.

3. Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына мәҗбүри иминләштерү керетемнәренең һәм Татарстан Республикасының республика бюджетыннан ассигнованиеләрнең күләмнәре, иминләштерү кертемнәрен түләүче һәм аларны түләүдән азат ителүче эш бирүчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең категорияләре, Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондының керемнәре һәм чыгымнары күләме Татарстан Республикасы законнарында билгеләнә.

4. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды дәүләт финанс ресурсларына кертелә, аның акчаларын барлыкка китерү һәм тоту тәртибе әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондының хисап елында файдаланылмаган акчалары кире алынмый һәм алар киләсе финанс елына күчерелә.

5. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондының акчалары салым салудан законнар нигезендә азат ителә.

23 статья. Эшсез гражданнарны һөнәри әзерләү, белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәтү

1. Эшсез гражданнарны һөнәри әзерләү, белгечлекләрен арттыру һәм яңа һөнәргә өйрәтү эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча тормышка ашырылырга мөмкин, әгәр:

гражданның тиешле һөнәри белгечлеге булмаганга күрә, аңа яраклы эшне сайлап алу мөмкинлеге табылмаса;

гражданның һөнәри күнекмәләренә туры килерлек эшнең булмавы аркасында һөнәрен (белгечлеген, шөгыленең төрен) үзгәртергә кирәк булса;

граждан элеккеге һөнәре (белгечлеге) буенча эшне башкару сәләтен югалткан булса.

2. Эшсез гражданнарны һөнәри әзерләү, аларның белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәтү эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары белән төзелгән шартнамәләр нигезендә һөнәри һәм өстәмә белем мәгариф учреждениеләрендә, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының уку үзәкләрендә яки башка мәгариф учреждениеләрендә, оешмаларның мәгариф бүлекчәләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Өстенлекле рәвештә һөнәри әзерлек үтү, белгечлеген күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү буенча хокукына түбәндәгеләр ия булалар: эшсез инвалидлар, эшсезлекнең алты ай вакыты узгач та эшсез булган гражданнар, хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнар, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең һәм хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданнарның хатыннары (ирләре), гомуми белем учреждениеләрендә укуларын тәмамлаганнар, шулай ук беренче мәртәбә эш эзләүче (элегрәк бер дә эшләмәгән), һөнәре (белгечлеге) булмаган гражданнар.

4. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары таләбе буенча мәгариф учреждениеләре чыгарылышның һөнәри белгечлек структурасы турында һәм, укуларын тәмамлап, эшкә урнашырга ихтыяҗы булганнарның саны турында мәгълүмат бирәләр.

24 статья. Җәмәгать эшләрен оештыру

1. Җирле администрацияләр һәм җирле үзидарә органнары эш

белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тәкъдиме буенча һәм алар катнашында халыкны вакытлыча эш белән тәэмин итү максатларында үз милекләрендәге оешмаларда, ә шартнамәләр буенча - башка оешмаларда да түләүле җәмәгать эшләрен башкаруны оештыралар.

Хезмәт эшчәнлегенең һәркемгә яраклы, кагыйдә буларак, хезмәткәрләрнең алдан һөнәри әзерлекле булуын таләп итмәүче, социаль файдалы юнәлеше булган һәм эш эзләүче затларны вакытлыча эш белән тәэмин итү өчен оештырылучы төрләре әлеге Законга карата җәмәгать эшләре, дип санала.

Һәлакәтләрнең, табигый бәла-казаларның, афәтләрнең һәм башка гадәттән тыш вәзгыятьләрнең нәтиҗәләрен кичекмәстән бетерүгә бәйле, хезмәткәрләрнең махсус әзерлеген, шулай ук бик аз вакыт эчендә югары квалификацияле һәм җаваплы чаралар күрүне таләп итәр торган эшчәнлек төрләре җәмәгать эшләренә кертелми.

2. Җәмәгать эшләрендә катнашырга теләүче затлар белән алты айга кадәр вакыты билгеләнгән хезмәт шартнамәсе төзелә. Эшсезлек пособиесе алмаучы эшсез гражданнар, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында эшсез буларак алты айдан артыграк исәптә торган гражданнар мондый шартнамә төзүдә өстенлекле хокуктан файдаланалар.

Җәмәгать эшләренә теге яисә бу рәвешле мәҗбүриләү рөхсәт ителми.

3. Җәмәгать эшләре белән шөгыльләнүче гражданнарга хезмәт өчен түләү законнарда билгеләнгәнчә башкарыла.

Эшсезләр арасыннан булган гражданнарның җәмәгать эшләрендә катнашулары чорына эш белән тәэмин итү фонды акчалары исәбеннән хезмәт хакларына аларга тиешле эшсезлек пособиесе күләмендә өстәмә түләү билгеләнә. Бу чакта җәмәгать эшләрендә катнашу турында вакыты билгеләнгән хезмәт шартнамәсе төзегән көннән өстәмә түләүләрне бирүнең максималь чоры суммарлап исәпләгәндә алты айдан да артмаска тиеш.

4. Җәмәгать эшләре белән шөгыльләнүче гражданнарга хезмәт турындагы һәм социаль-иминләштерү турындагы законнар кагыла.

5. Җәмәгать эшләрен финанслау шушы эшләр оештырылучы оешмаларның акчалары исәбеннән һәм, кирәк чагында, җирле бюджет һәм Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды акчалары исәбеннән финанслана.

## V бүлек. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары

**25 статья.** Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары

1. Татарстан Республикасы территориясендә халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт сәясәтен тормышка ашыру өчен эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарының түбәндәге составта бердәм системасы булдырыла:

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт үзәкләре - районнарда һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрдә.

2. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары һәм эш бирүчеләрнең эш белән тәэмин итү һәм хезмәт турындагы законнарны үтәүләрен тикшереп торучы хокук инспекцияләре төзелергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты һәм аның урыннардагы органнары, дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары белән бергә, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү әлкәсендә дәүләт сәясәтен әзерлиләр һәм гамәлгә ашыралар.

4. Шәһәрләрдәге һәм районнардагы эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары җирле администрацияләргә дә, шулай ук Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитетына да буйсыналар.

5. Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт комитеты үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланган нигезләмә буенча гамәлгә ашыра.

## VI бүлек. Халыкны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең катнашуы

<u>26 статья.</u> Халыкны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәм күрсәтүе

1. Эш бирүчеләр дәүләтнең халыкны эш белән тәэмин итү сәясәтен тормышка ашыруга түбәндәге нигезләрдә ярдәм күрсәтәләр:

хезмәт мөнәсәбәтләрен законнар нигезендә җайга салучы шартнамәләр (контрактлар) шартларын үтәү;

җитештерү туктатып торылганда яисә хезмәткәрләр эштән азат ителгәндә хезмәт турындагы законнарда, хезмәт иясләрен яклау буенча коллектив шартнамәләрдә һәм килешүләрдә каралган гамәлләрне тормышка ашыру;

эштән азат ителгән хезмәткәрләрне эшкә урнаштырганда, һөнәри әзерләгәндә ярдәм күрсәтү һәм оешмалар, башка эш бирүчеләр акчалары исәбеннән аларга законнарда билгеләнгәннән тыш өстәмә матди ярдәм күрсәтү;

эшләүчеләрнең һөнәри әзерлеге, белгечлеген күтәрү өчен һәм аларны яңа һөнәргә өйрәтү өчен шартлар тудыру. Салым салынучы табышны исәпләп чыгарган чакта оешмаларның балансстагы табышының суммасы эш бирүчеләрнең шушы максатларга тотылган акчалары суммасына киметелә;

хезмәткәрләрнең һөнәри потенциалын саклап калуны һәм нәтиҗәле файдалануны, аларны социаль яклауны, аларның хезмәт шартларын яхшыртуны һәм башка ташламаларны күз алдында тотучы социаль оештыру планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарның эшкә урнаштыруның билгеләнгән квотасын үтәү, шул исәптән мондый гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) законнар нигезендә резервлау.

2. Эш бирүчеләр эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарына ай саен түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

әлеге оешмага карата бөлгенлеккә төшү (банкротлык) процедураларын куллану турындагы белешмәләрне, шулай ук вакантлы эш урыннары (вазыйфалары), социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә алу квотларын үтәү, шул исәптән инвалидларны эшкә алу квотасын, күрсәтелгән затларны эшкә алу квотасын үтәмәгән-

121



дә яисә үтәү мөмкинлеге булмаганда, Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына мәҗбүри иминләштерү кертемнәрен күчерү һәм мәҗбүри түләү кертү турында мәгълүмат.

3. Эш бирүчеләр хезмәткәрләрнең күпләп эштән чыгарылу ихтималы турындагы, моңа эләгергә мөмкин булган хезмәткәрләрнең саны һәм категорияләре турындагы мәгълүматны һәм аның гамәлгә ашырылу вакытын кимендә өй ай алдан тулы күләмдә эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарына һәм һөнәр берлекләре органына яисә хезмәткәрләрнең башка вәкиллекле органына тапшыралар.

4. Эш бирүчеләр әлеге җитештерүдә һөнәри авыру алган яисә гарипләнгән хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру уңаеннан махсус эш урыннары булдыруга һәм аларга һөнәри әзерлек бирүгә, белгечлекләрен күтәрүгә, яңа һөнәргә өйрәтүгә эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тоткан чыгымнарны Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына акча күчерү юлы белән тулысынча кире кайтаралар.

5. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә алу квотасы үтәлмәгән яисә үтәлү мөмкинлеге булмаган очракта эш бирүчеләр эшкә урнашмаган һәр граждан өчен Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына квота кысаларында ай саен мәҗбүри түләү кертәләр.

Әлеге мәҗбүри түләүне кертү тәртибе һәм күләмнәре законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6. Башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме учреждениеләренең, алдан ук аларга заявка бирелеп, яңа гына укып чыккан белгечләрен эшкә алудан баш тарткан очракта, оешмалар Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү фондына шушы категория хезмәткәрнең уртача еллык хезмәт хакы күләмендә максатчан финанс кертемнәре ясыйлар.

7. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы җибәргән гражданны эшкә алганда эш бирүче, гражданны эшкә алу көнен күрсәтеп, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органына биш көн эчендә юлламаны кире кайтара.

Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы җибәргән гражданны эшкә алудан баш тарткан очракта, эш бирүче, эш белән тәэмин итү хезмәтенең юлламасында гражданның мөрәҗә-

гать иткән көне һәм эшкә алудан баш тартуның сәбәбе турында билге ясап, юлламаны гражданга кире кайтара.

8. Эш бирүчеләр әлеге статьяның 2,3,4 пунктларын үтәмәгән өчен Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына иминләштерү кертемнәренең дөрес исәпләнүе, тулысынча һәм вакытында түләнүе өчен законнарда билгеләнгәнчә җаваплы булалар.

<u>27 статья.</u> Эш бирүчеләрнең хокуклары

1. Эш бирүче турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать иткән гражданнарны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органының юлламасы булган гражданнар белән бертигез нигезләрдә эшкә кабул итәргә хокуклы.

2. Һөнәри гомуми белем учреждениеләрен тәмамлаганнар, ирегеннән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затлар өчен, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эшкә урнашуда кыенлыклар кичерүче гражданнарны билгеләнгән минималь саннан тыш өстәмә рәвештә эшкә урнаштырган эш бирүчеләр салым турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы булалар.

3. Эш бирүчеләр эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарыннан хезмәт базарының халәте турында мәгълүмат алырга хокуклы.

4. Кирәк чакта эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары оешмалардан җибәрелгән гражданнарны эш белән тәэмин итү максатларында алдан укытып куюга киткән чыгымнарны, шулай ук башка оешмалардан эштән чыгарылганнан соң үзләренә эшкә алынган гражданнарны укытуны оештыруга киткән чыгымнарны эш бирүчеләргә тулысынча яисә өлешчә компенсацияләргә мөмкин.

5. Эш бирүче эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органының гамәлләренә карата эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча югарырак органга, шулай ук судка законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## VП бүлек. Социаль гарантияләр һәм компенсацияләр

### 28 статья. Эшсезләрне социаль яклау гарантияләре

1. Дәүләт эшсезләргә түбәндәгеләрне гарантияли: эшсезлек пособиесе түләүне; эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек алу, белгечлеген күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорында стипендияләр түләүне; түләүле җәмәгать эшләрендә катнашу мөмкинлеген; эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тәкъдиме буенча эшкә урнашу өчен башка җиргә үз ихтыяры белән күчеп китүенә бәйле чыгымнарны түләүне.

2. Гражданның законда билгеләнгән тәртиптә эшсезлек пособиесе, стипендия алган, түләүле җәмәгать эшләрендә катнашкан вакыты, эш белән тәэмин итү юлламасы буенча икенче җиргә күчеп китү һәм эшкә урнашу өчен кирәкле вакыты, шулай ук хезмәткә вакытлыча сәләтсез булу чоры, йөклелек һәм бала табу буенча отпускта булу чоры , хәрби җыелуларга чакырылган вакыты, дәүләт вазыйфалары үтәү белән бергә хәрби хезмәткә әзерләнүгә бәйле гамәлләргә җәлеп ителү вакыты хезмәт стажын өзми һәм ул гомуми хезмәт стажына кертеп исәпләнелә.

3. Эшсез калган һәм рәсми рәвештә эшсез дип табылганчы 12 ай эчендә хезмәт хакы алмаган гражданнарга, хезмәткә вакытлыча сәләтсезлекнең факттагы көннәреннән чыгып, хезмәткә вакытлыча сәләтсез булып торган чор өчен халыкны Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды акчалары исәбеннән әлеге категория гражданнарга каралган эшсезлек пособиесе (стипендия) күләмендә түләү үткәрелә.

4. Эшсезләргә түләнүче пособиеләрнең һәм түләүләрнең барлык төрләре законда билгеләнгән тәртиптә индексацияләнә.

### 29 статья. Оешмалардан эштән чыгарылган хезмәткәрләргә ташламалар һәм компенсацияләр

Оешмалар ябылуга бәйле рәвештә, хезмәткәрләрнең саны (штаты) кыскару аркасында оешмалардан эштән чыгарылган хезмәткәрләргә хезмәт шартнамәсен өзгәндә хезмәт турындагы законнар

нигезендә ташламалар һәм компенсацияләр бирелә.

Ябылучы оешмаларның эштән чыгарылган гражданнарына түләрлек акчалары булмаса, компенсацияләр түләү законда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла.

30 статья. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорында гражданнарга түләнүче стипендияләр күләме

1. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорында түбәндәге гражданнарга стипендия түләнә:

эшсезлеккә кадәрге 12 ай эчендә оешмадан эштән чыгарылганнарга һәм бу чорга тулы эш көне (атнасы) шартларында яисә тулы булмаган эш көне (атнасы) шартларында тулы эш көненә (атнасына) күчереп исәпләгәндә кимендә 26 календарь атна түләүле эш чоры булганнарга - соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен исәпләнелгән хезмәт хакының 75 проценты күләмендә, әмма ул Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан артыграк булмаска, Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 процентыннан да ким булмаска тиеш. Бу чакта стипендиянең минималь күләме хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән күләменнән ким булмаска тиеш;

озак вакыт (бер елдан артыграк) эшләми торганнан соң хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылучыларга, беренче мәртәбә эш эзләүчеләргә (элегрәк бер дә эшләмәгәннәргә), шулай ук эшсезлеккә кадәрге 12 ай эчендә оешмалардан эштән чыгарылганнарга һәм бу чорга 26 календарь атнадан кимрәк түләүле эше булганнарга - тиешле юнәлештәге уку йортлары өчен дәүләт тарафыннан билгеләнгән стипендия күләмендә, әмма шушы категория гражданнар өчен каралган эшсезлек пособиесе күләменнән кимрәк түгел;

җитештерүдәге бәхетсезлек очрагы яисә һөнәри авыру аркасында элекке эшен үтәү сәләтен югалтканнарга - тиешле оешма акчалары исәбеннән - соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен

нигезендә ташламалар һәм компенсацияләр бирелә.

Ябылучы оешмаларның эштән чыгарылган гражданнарына түләрлек акчалары булмаса, компенсацияләр түләү законда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла.

30 статья. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорында гражданнарга түләнүче стипендияләр күләме

1. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорында түбәндәге гражданнарга стипендия түләнә:

эшсезлеккә кадәрге 12 ай эчендә оешмадан эштән чыгарылганнарга һәм бу чорга тулы эш көне (атнасы) шартларында яисә тулы булмаган эш көне (атнасы) шартларында тулы эш көненә (атнасына) күчереп исәпләгәндә кимендә 26 календарь атна түләүле эш чоры булганнарга - соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен исәпләнелгән хезмәт хакының 75 проценты күләмендә, әмма ул Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан артыграк булмаска, Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 процентыннан да ким булмаска тиеш. Бу чакта стипендиянең минималь күләме хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән күләменнән ким булмаска тиеш;

озак вакыт (бер елдан артыграк) эшләми торганнан соң хезмәт эшчәнлеген торгызырга омтылучыларга, беренче мәртәбә эш эзләүчеләргә (элегрәк бер дә эшләмәгәннәргә), шулай ук эшсезлеккә кадәрге 12 ай эчендә оешмалардан эштән чыгарылганнарга һәм бу чорга 26 календарь атнадан кимрәк түләүле эше булганнарга - тиешле юнәлештәге уку йортлары өчен дәүләт тарафыннан билгеләнгән стипендия күләмендә, әмма шушы категория гражданнар өчен каралган эшсезлек пособиесе күләменнән кимрәк түгел;

җитештерүдәге бәхетсезлек очрагы яисә һөнәри авыру аркасында элекке эшен үтәү сәләтен югалтканнарга - тиешле оешма акчалары исәбеннән - соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен

125



исәпләнелгән уртача хезмәт хакының 100 проценты күләмендә, әмма хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән күләменнән кимрәк һәм республикада урнашкан уртача хезмәт хакы күләменнән артыграк түгел.

2. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы нигезендә һөнәри әзерлек, белгечлеген күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү үтүче гражданның асравында башка затлар булганда, стипендиясе Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 10 проценты күләмендә арттырыла, әмма ул алда күрсәтелгән һәр зат өчен хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән ким булмаска тиеш (гаиләдә бердәнбер туендыручы сыйфатында булган укучыга стипендия ике мәртәбәгә арттырыла).

Бу чакта стипендияне арттыруның максималь күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 30 процентыннан артмаска тиеш.

Стипендиянең һәм өстәмә түләүләрнең гомуми суммасы элеккеге эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләменнән артмаска тиеш.

3. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тарафыннан һөнәри әзерлеккә, белгечлеген күтәрүгә һәм яңа һөнәргә өйрәнүгә җибәрелгән гражданнарга укуларының беренче көненнән үк стипендия түләнә. Бу чакта ябылу, үзгәртеп кору һәм штат кыскарту аркасында оешмалардан эштән чыгарылган һәм эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тарафыннан һөнәри әзерлеккә,белгечлеген күтәрүгә һөм яңа һөнәр өйрәнүгә җибәрелгән хезмәт турындагы законнарда каралган гарантияле уртача хезмәт хакын алу чоры узганнан соң беренче көненнән үк стипендия исәпләнелә башлый.

4. Өлгереше канәгатьләнерлек булмаган очракта яисә сәбәпсез дәрес калдырганнарга стипендия 25 процентка киметелергә яисә бер айга кадәр бөтенләй бирелмәскә мөмкин.

5. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча һөнәри әзерлек, белгечлеген күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәнү чорына гражданнарга түләнүче стипендиядән хөкем карары яисә суд карары нигезендә тотып калуларның барлык төрләре (алиментлар, зыянны түләүләр һәм башка тотып калулар) алына, әмма ул алынучы стипендиянең яртысыннан артмаска тиеш.

6. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары

кирәк чакта юл хакын (укыган җиргә бару һәм аннан кайту) һәм һөнәри әзерлек алу өчен, белгечлеген күтәрү яисә яңа һөнәргә өйрәнү өчен башка җиргә үзләре җибәргән гражданнарның көн күрүе белән бәйле чыгымнарын түләргә мөмкин.

31 статья. Эшсезлек пособиесенең күләмнәрен билгеләү тәртибе

1. Теләсә нинди нигездә эштән чыгарылган, әмма эшсез калганчы 12 ай дәвамында тулы эш көне (атнасы) шартларында яисә тулы булмаган эш көне (атнасы) шартларында тулы эш көненә (атнасына) күчереп исәпләгәндә кимендә 26 календарь атна түләүле эше булган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга эшсезлек пособиесе соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай эчендә исәпләнелгән уртача хезмәт хакына процент нисбәтләрендә билгеләнә.

2. Башка барлык очракларда да, шул исәптән һөнәре (белгечлеге) булмаган һәм беренче мәртәбә эш эзләүче (элегрәк бер дә эшләмәгән), озак тәнәфестән соң (бер елдан артыграк) хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрергә омтылучы гражданнарга, шулай ук эшсезлеккә кадәрге 12 ай дәвамында оешмалардан эштән чыгарылганнарга һәм бу чордагы эше 26 календарь атнадан да ким булганнарга Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 проценты күләмендә, әмма хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән кимрәк булмаган эшсезлек пособиесе билгеләнә.

3. Эшсезнең асравында башка затлар булганда, һәр зат саен Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 10 проценты күләмендә пособие арттырыла, әмма ул хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменең яртысыннан кимрәк булмаска тиеш (гаиләдә бердәнбер туендыручы сыйфатында булган эшсезгә эшсезлек пособиесе икеләтелгән күләмдә түләнә).

Бу чакта өстәмә түләүләрнең максималь күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 30 процентыннан артмаска тиеш, ә эшсезлек пособиесенең һәм өстәмәнең максималь суммасы элекке эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләменнән артмаска тиеш.

Әгәр ата-аналарның икесе дә эшсез булсалар, алар асравындагы затларга бирелә торган пособие күләме ата-аналарның һәркайсына арттырыла.

4. Хөкем карары яисә суд карары нигезендә эшсезлек пособиесеннән тотып калуларның барлык төрләре (алиментлар, зыянны түләүләр һәм башка тотып калулар) башкарыла, әмма ул алынучы эшсезлек пособиесенең яртысыннан артмаска тиеш.

32 статья. Эшсезлек пособиесен түләү шартлары һәм вакыты

1. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга эшсезлек пособиесе түләнә.

2. Эшсөзлек пособиесен билгеләү турындагы карар әлеге Законның 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә гражданнарны эшсез дип тану хакындагы карар белән бер үк вакытта кабул ителә.

3. Пособие түләү чоры, әлеге Законда каралган очраклардан тыш, 18 календарь ай дәвамында суммар күләме буенча 12 айдан да артмаска тиеш.

4. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга эшсезлек пособиесе аларны эшсезләр дип таныган көннән үк исәпләнелә башлый.

Ябылу,үзгәртеп кору һәм штат кыскарту аркасында оешмалардан эштән азат ителгән һәм моннан соң ике атна эчендә эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарында теркәлгән, әмма хезмәт турындагы законнарда гарантияләнгән уртача хезмәт хакын алган вакыт эчендә эшкә урнашмаган гражданнар өчен эшсезлек пособиесе бу чор узганның беренче көненнән үк исәпләнелә башлый.

5. Эшсезлекнең 18 календарь ае узганнан соң түләүле яраклы эш бирелмәгән очракта, эшсез Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 проценты күләмендә эшсезлек пособиесен кабат алырга хаклы, әмма бу пособие хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән кимрәк булмаска тиеш.

6. Әгәр эшсезләр эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары билгеләгән вакытта аена кимендә ике мәртәбә теркәлү узсалар, эшсезлек пособиесе аена ике мәртәбәдән дә кимрәк түләнми.

7. Дәүләт хакимиятенең җирле органнары пособиеләр түләүнең озаграк вакытын да билгеләргә яисә пособиеләрне тиешле бюджетларның акчалары исәбеннән түләүне озайтуны карарга мөмкин.

33 статья. Картлык (яше буенча) пенсиясе хокукын бирүче эш стажы булган гражданнарга эшсезлек пособиесен түләү чорын озайту тәртибе

1. Гомуми хезмәт стажлары пенсия турындагы законнар нигезендә картлык (яше буенча) пенсиясе алу хокукы биреп тә (моңа ташламалы шартлардагы пенсияләр дә керә), пенсия яше җитмәгән гражданнарга эшсезлек пособиесен түләү чоры, билгеләнгән 12 айдан тыш, таләп ителүче эш стажыннан артыграк һәр эшләгән елы әчен икешәр атнага озайтыла.

Эшсезлек пособиесен түләүнең гомуми чоры 36 календарь ай дәвамында суммар исәпләгәндә 24 календарь айдан артмаска тиеш.

2. Оешма ябылу, анда эшләүчеләр санын яисә штатларын кыскарту аркасында эштән чыгарылган, хезмәт эшчәнлегендә өзеклекләр булу-булмауга бәйсез рәвештә, картлык буенча (яше буенча) тулы пенсиягә чыгарлык эш стажына ия булган (ташламалы шартлардагы пенсияне дә кертеп) һәм эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган эшсез гражданнарга эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тәкъдиме буенча, үз ризалыклары белән пенсия вакытыннан алда рәсмиләштерелә, әмма бу гамәл пенсиягә чыгуның законнарда билгеләнгән вакытыннан ике елдан да иртәрәк башкарылмаска тиеш.

3. Пенсиягә алданрак чыгуга бәйле чыгымнар, соңыннан Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондыннан түләттерү шарты белән, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды акчалары исәбеннән түләнә.

34 статья. Теләсә нинди нигездә оешмалардан эштән чыгарылган, хәрби хезмәттән һәм эчке эшләр органнарыннан чыгарылган гражданнарга эшсезлек пособиесе күләме

Эшсезлеккә кадәрге 12 ай эчендә теләсә нинди нигездә оеш-

129



малардан чыгарылган һәм шул чорда тулы эш көне (атнасы) шартларында яисә тулы булмаган эш көне (атнасы) шартларында тулы эш көненә (атнасына) күчереп исәпләгәндә кимендә 26 календарь атна түләүле эше булган гражданнарга, шулай ук хәрби хезмәттән һәм эчке эшләр органнарыннан чыгарылганнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылганнарга эшсезлек пособиесе түбәндәгечә исәпләнелә:

эшсезлекнең беренче өч аенда - соңгы эш (хезмәт) урынында соңгы өч ай өчен исәпләнелгән уртача хезмәт хакының (барлык акчалата алынганның) 75 проценты күләмендә;

шуннан сонгы дүрт ай эчендә - 60 процент күләмендә;

соңрак - 45 процент күләмендә, әмма башка барлык очракларда Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан артыграк һәм Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 процентыннан ким булмаска тиеш. Бу чакта эшсезлек пособиесенең минималь күләме хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән ким булмаска тиеш.

35 статья. Эшсез гражданнарның башка категорияләренә эшсезлек пособиесе күләме

1. Беренче мәртәбә эш эзләүче (элегрәк бер дә эшләмәгән), озак тәнәфестән соң (бер елдан артыграк) хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерергә омтылган гражданнарга, шулай ук теләсә нинди нигездә эштән азат ителгән, әмма эшсез калганчы 12 ай дәвамында 26 календарь атна түләүле эше булмаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 проценты күләмендә эшсезлек пособиесе түләнә, әмма ул хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән ким булмаска тиеш.

2. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы нигезендә һөнәри әзерлеген, белгечлеген күтәрүне һәм яңа һөнәргә өйрәнүне тәмамлаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган түбәндәге гражданнарга эшсезлек пособиесе түләнә:

эшсез калганчы 12 ай эчендә теләсә нинди нигездә оешмалардан эштән чыгарылганнарга һәм бу чорда тулы эш көне (атнасы)

130



шартларында яисә тулы булмаган эш көне (эш атнасы) шартларында тулы эш көненә (атнасына) күчереп исәпләгәндә кимендә 26 календарь атна түләүле эше булганнарга эшсезлекнең беренче өч аенда - соңгы эш урыны буенча соңгы өч ай өчен исәпләнелгән уртача хезмәт хакының 75 проценты түләнә, ә аннан соңгы дүрт айда - 60 проценты, соңрак - 45 проценты, башка барлык очракларда Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумнан артыграк һәм Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 процентыннан ким булмаска тиеш. Бу чакта эшсезлек пособиесе хезмәт өчен түләүнең Федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән ким булмаска тиеш;

эшсез калганчы 12 ай эчендә теләсә нинди нигездә оешмалардан чыгарылганнарга, әмма бу чорда 26 календарь атна түләүле эш атнасы булмаганнарга, беренче мәртәбә эш эзләүчеләргә (элегрәк бер дә эшләмәгәннәргә) һәм һөнәре (белгечлеге) булмаганнарга, шулай ук озак тәнәфестән соң (бер елдан артыграк) хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерергә омтылганнарга - Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнелгән көн күрерлек минимумның 20 проценты күләмендә, әмма ул хезмәт өчен түләүнең Федераль законнарында билгеләнгән минималь күләменнән ким булмаска тиеш.

<u>36 статья.</u> Эшсезлек пособиесен түләүне туктатып тору, туктату һәм аның күләмен киметү

1. Эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тарафыннан эшсезлек пособиесен түләү туктатып торылырга, туктатылырга яисә аның күләме киметелергә мөмкин.

2. Пособиене түләү түбәндәге очракларда өч айга кадәрле туктатып торылырга мөмкин:

хезмәт дисциплинасын бозган өчен һәм хезмәт турындагы законнарда каралган башка гаепле гамәлләр өчен соңгы эш урыныннан чыгарылганда, шулай ук эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары укырга җибәргән граждан укыган урыныннан гаепле гамәлләр аркасында чыгарылганда;

эшсезлек чорында яраклы эшнең ике вариантыннан баш тартканда;

беренче мәртәбә эш эзләүче (элегрәк бер дә эшләмәгән), һөнәре (белгечлеге) булмаган, озак тәнәфестән соң (бер елдан артыграк) хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерергә омтылучы граждан-нар эшсезлекнең өч ае узганнан соң эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча укырга барудан баш тартканда;

эшсез кабат теркәлү шартларын һәм чорларын мәгълүм сәбәп-ләрсез бозганда. Бу чакта эшсезлек пособиесен түләү эшсез ка-бат теркәлүгә килмәгәннең икенче көненнән туктатып торыла;

граждан эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт ор-ганнары юлламасы буенча укуын үз белдеге белән туктатканда.

Эшсезлек пособиесен түләү туктатып торылган чор эшсезлек пособиесен түләүнең гомуми чорына кертелә һәм гомуми хезмәт стажына кертелми.

3. Эшсезлек пособиесен түләү, эшсезне исәпкә алу белешмә-ләреннән төшереп калдыру белән бергә, түбәндәге очракларда туктатыла:

әлеге Законның 2 статьясында каралган сәбәпләр аркасында эшсез эш белән мәшгуль дип танылганда;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары юлламасы буенча, стипендия түләнелгән килеш, һөнәри әзерлек, белгечлеген күтәрү яисә яңа һөнәргә өйрәнү узганда;

эшсезлек пособиесен ялган юл белән алырга омтылганда яисә алганда;

эшсезлек пособиесен алучы зат ирегеннән мәхрүм итү рәве-шендә җәзага тартылганда;

эшсез башка җиргә күчеп киткәндә;

пенсия турындагы законнар нигезендә картлык (яше буенча) пенсиясе, эшләгән еллары өчен пенсия билгеләнгәндә.

4. Эшсезлек пособиесенең күләме түбәндәге очракларда бер айга кадәр чорга 25 процентка киметелергә мөмкин:

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары җибәргәннән соң эш бирүче белән эшкә урнашу турында сөйләшү өчен өч көн буена сәбәпсез килмәгәндә;

эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнарына эшкә (укуга) юллама алырга килүдән сәбәпсез баш тартканда.

5. Эшсезлек пособиесе түбәндәге чорларда түләнми:

эшсез эшкә сәләтен вакытлыча югалтканда;

йөклелек һәм бала табу отпускы вакытында;

һөнәри белемнең кичке һәм читтән торып уку учреждениеләрендә укуы сәбәпле даими яшәү урыныннан китеп торганда;

эшсез хәрби җыелуларга чакырылганда, хәрби хезмәткә әзерлек белән, дәүләт вазыйфаларын башкару белән бәйле гамәлләргә җәлеп ителгәндә.

Әлеге чорлар эшсезлек пособиесе түләүнең гомуми чорына кертелми һәм аны озайта гына.

6. Эшсезлек пособиесен түләүне туктатып тору, туктату яисә аның күләмен киметү турындагы карарлар, эшсезгә һичшиксез хәбәр иткәннән соң, эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы тарафыннан кабул ителә һәм аларга карата билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

37 статья. Матди һәм башка ярдәм

Әлеге Закон нигезендә билгеләнгән эшсезлек пособиесен түләү чоры үтү сәбәпле аны алу хокукын югалткан эшсез гражданнарга, шулай ук эшсез асравындагы башка затларга эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органнары тарафыннан матди һәм башка ярдәм күрсәтелергә мөмкин, моңа мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләреннән, коммуналь хезмәтләрдән, җәмәгать транспортыннан, сәламәтлек саклау һәм җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтүләреннән файдаланган өчен дотацияләр дә керә.

Эшсез асравындагы затларга 18 яше тулмаган (укучылар өчен - 24 яшь), эшсез граждан акчасына көн күрүче, мөстәкыйль керем чыганагы булмаган һәм эшсезнең туганы булган затлар керә.

Эшсез асравындагы затларга түбәндәгеләр керми:

стипендияләр, пенсияләр һәм эшсезлек пособиеләре алучылар;

дәүләт асравында булучылар (башлангыч һөнәри белем учреждениеләре укучылары, балалар йортларында һәм сабый бала йортларында тәрбияләнүчеләр);

махсус мәктәпләрнең укучылары, интернат йортлардагы балалар (алар өчен опекуннарыннан түләү алынмаса), шулай ук тулысынча дәүләт тәэминатында булган мәктәпләр каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләр.

Кирәк чагында эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәү-

ләт органнары һөнәри әзерлеккә, белгечлеген күтәрүгә һәм яңа һөнәр өйрәнүгә җибәрелгән гражданнарга да матди ярдәм күрсәтергә мөмкин.

38 статья. Эш югалту очрагын ихтыярый социаль иминләштерү

Гражданнар эшсез калу очрагын ихтыярый иминләштерү турында иминләштерү оешмалары белән шартнамә төзи алалар.

Иминләштерү тәртибе, эзлеклелеге һәм шартлары законнар белән билгеләнә.

VШ бүлек. Әлеге Законны үтәүне тикшереп
тору һәм аны бозган өчен җаваплылык

39 статья. Әлеге Законны үтәүне тикшереп торучы органнар

Әлеге Законның үтәлешен шуңа вәкаләтле дәүләт органнары Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә тикшереп торалар.

40 статья. Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

Әлеге Законны бозган өчен гаепле затлар законнар нигезендә җаваплы булалар".

2 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына үз норматив-хокукый актларын әлеге Законга туры китерүне йөкләргә.

3 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 3 июле
N I703